МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.01.2016 г.Казань № 5/2-пр

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2015-2017 нче елларда Татарстан Республикасында үз эшен башлаучы фермерларга ярдәм күрсәтү» ведомство программасын раслау турында» 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министырлыгыныц «Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2012 елның 28 февральдәге 166 номерлы карарын гамәлгә ашыру турында» 2012 елның 22 мартындагы 197 номерлы боерыгын үтәү йөзеннән һәм Россия Федерациясенең Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы субъекты арасындагы «Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетына субсидия тәкъдим итү турында» 2015 елның 5 мартындагы 48/17-с номерлы Килешү нигезендә,

б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «2015-2017 нче елларда Татарстан Республикасында үз эшен башлаучы фермерларга ярдәм күрсәтү» ведомство программасын раслау турында» 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 нче номерлы кушымтаны яңа редакциядә бирергә (кушымта бирелә);

1.2. 3 нче номерлы кушымтаны яңа редакциядә бирергә (кушымта бирелә);

1.3. 5 нче номерлы кушымтаны яңа редакциядә бирергә (кушымта бирелә).

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р. Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр М.Г. Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына 2нче кушымта (ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының 2016 елның 26нчы гыйнварындагы 5/2-пр номерлы боерыгы редакциясендә)

Крестьян (фермер) хуҗалыкларны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирү турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. «Крестьян (фермер) хуҗалыкларны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар бирү Һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирү турында Нигезләмә» (алда – Нигезләмә) Россия Федераңиясе авыл хуҗалыгы Министырлыгының «Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2012 елның 28 февралендәге 166 номерлы карарын гамәлгә ашыру турында» 2012 елның 22 мартындагы 197 номерлы боерык һәм әлеге боерык белән расланган «2015-2017 нче елларда Татарстан Республикасында үз эшен башлаучы фермерларга ярдәм күрсәтү» ведомство программа (алда – Программа) нигезендә әзерләнде.

Нигезләмә грантның һәм (яки) акчалата ярдәм күрсәтүнең тәртибен, проектларның сайлап алыну критерийларын, сайлап алу бәйгесенең максатлырын, шартларын, оештыру процедурасын, һәм шулай ук, крестьян (фермер) хуҗалыкларны булдыру һәм аларның үсешенә каралган Һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәмне бирү шартларын грант ияләре бозу очрагында акчалата ярдәмне кире кайтаруның тәртибен билгели.

Әлеге Нигезләмәдә кулланылган төп төшенчәләр:

**үз эшен башлаучы фермер** – әлеге Нигезләмә буенча сайлауны узган Программада катнашучы;

**гариза бирүче** - Россия Федерациясе законнарына туры китерелеп оештырылган крестьян (фермер) хуҗалык (алда – КФХ) бышлыгы булган, Программада катнашучы итеп танылу өчен конкурс комиссиясенә заявка тапшырган һәм Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгы (алда – Министрлык) билгеләгән таләпләргә туры килүче Россия Федераңиясе гражданины;

**крестьян (фермер) хуҗалыкларны булдыру һәм аларның үсешенә бирелгән грант** – дәүләт ярдәме формасында Министрлык тарафыннан үз эшен башлаучы фермерның кредит оешмасында ачылган счетына күчереләчәк, аның булачак чыгымнарын (расланган чыгымнар планы нигезендә) уртак финанслауга юнәлгән һәм Программа нигезендә башка дәүләт ярдәме юнәлешләре кысаларында кире кайтарылмый торган акчалар (алда – грант);

**көнкүрешне төзекләндерүгә каралган бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм** – дәүләт ярдәме формасында Министрлык тарафыннан үз эшен башлаучы фермерның булачак чыгымнарын уртак финанслауга юнәлгән кредит оешмасында ачылган счетына күчереләчәк һәм аның расланган чыгымнар планы нигезендә торак һәм көнкүреш шартларын яхшыртуга каралачак акчалар;

**ведомствоара конкурс комиссиясе –** КФХ булдыру һәм үстерү өчен грантлар һәм (яки) үз эшләрен башлаучы фермерларга көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирүгә КФХ проектларын сайлап алу өчен төзелгән комиссия (алда – конкурс комиссиясе);

**ведомствоара конкурс комиссиясе каршындагы эксперт совет –** Министрлык тарафыннан заявкаларга һәм КФХ булдыру һәм үстерүөчен грантлар һәм (яки) үз эшләрен башлаучы фермерларга көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм алу документларына экспертиза ясау советы (алда – эксперт совет);

**чыгымнар планы** – заявка бирүче тарафыннан төзелеп, грантның һәм (яки) акчалата ярдәмнең куллану юнәлешен ачыклаган статьялар буенча чыгымнар сметасы (алда – чыгымнар планы).

1.2. Конкурс комиссиясе тарафыннан раслаган заявкасы булган үз эшен башлаучы фермерга грант һәм (яки) акчалата ярдәм бирелә.

1.3. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны Министрлык башкара.

1.4. Чыгымнар планында күрсәтелгән эшләнәчәк эшләрнең, сатып алына торган җиһазларның бәясеннән 10 проценттан да ким түгел өлешен шәхси акчаларыннан түләргә ризалык биргән үз эшләрен башлаучы фермерларга грант һәм (яки) акчалата ярдәм тәкъдим ителә.

Россия Федерациясе законнары нигезендә грант һәм (яки) акчалата ярдәм хисабына алынган милекне сату, бүләкләү, башка затларга арендага яки фадаланырга бирү, алыштыру яки пай рәвешендә бирү, өлеш итеп кертү грант һәм (яки) акчалата ярдәм алу көненән башлап 10 ел дәвамында рөхсәт ителми.

Грант һәм (яки) акчалата ярдәм бирү турында мәгълүмат Министрлыкның http://argo.tatarstan.ru/ официаль сайтында, «Интернет» телекоммуникацион-мәгълүмати челтәренең «Фермерларга, сельхозкооперативларга грантлар һәм ЛПХ субсидияләр» бүлегендә «2015-2017 нче елларда Татарстан Республикасында үз эшен башлаучы фермерларга ярдәм күрсәтү» бүлекчәсендә урнаштырылган (алда - Министрлыкның официаль сайты http://argo.tatarstan.ru/).

## 2. Программада катнашучыларга (заявка тапшыручыларга) карата таләпләр

2.1. Россия Федерациясе законнарына туры китерелеп оештырылган КФХ башлыгы булган Россия Федерациясе гражданины (алда – заявка тапшыручы) конкурс комиссиясенә заявка белән түбәндәге шартларны үтәүне раслаучы документлар тапшырырга мөмкин.

2.1.1. КФХ башлыгы булудан тыш, заявка тапшыручы соңгы өч ел дәвамында шәхси эшмәкәр буларак эшмәкәрлек эшен башкармаска һәм (яки) коммерция оешмасының оештыручысы (катнашчысы) булмаска тиеш.

Крестьян (фермер) хуҗалыкларны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар бирү һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм күрсәтү конкурсында катнашу өчен завка тапшыручы соңгы өч ел дәвамында эшмәкәрлек эшчәнлеге 6 ай күләменнән артмаса гына конкурс комиссиясенә катнашу заявкасын тапшырырга мөмкин;

2.1.2. Заявка тапшыручы үткәндә:

а) КФХны булдыру һәм үстерүгә грант иясе;

б) гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грант иясе;

в) КФХ буларак регистрация үтеп, аның башлыгы булганчы эшсез гражданнарга үз-үзләренә шөгел табуда ярдәм очен түләүләр иясе,

г) хуҗалык буларак регистрация үтеп, аның башлыгы булганчы эшмәкәрлек эшчәнлегенең башлангыч этабын оештыруга финанс ярдәм буларак субсидия яки гарнт иясе;

д) үз эшләрен башлаучы фермерларга көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата ярдәм иясе булмаска тиеш.

Заявка тапшыручы, әлеге бүлекнең 2.1.2. өлешендәге «в» һәм «г» пунктларында ачыкланган, хуҗалыкны оештыру һәм үстерүгә каралган бер тапкыр бирелә торган түләүләргә ия булып һәм бер үк чыгымнарны күрсәтелгән түләүләр хисабына финанслауны карамаган очракта конкурста катнашу мөмкинлеге бар.

2.1.3. Заявка тапшыручы авыл яки Татарстан Республикасында республика әһәмиятенә ия булмаган шәһәр җирлекләрендә теркәлү көненнән заявка тапшыру моментына кадәр 24 ай вакыт узмаган очракта КФХ башлыгы була ала;

2.1.4. Заявка тапшыручы авыл хуҗалыгы өлкәсендәге махсус урта яки югары белемле, яки авыл хуҗалыгы белгечлеге буенча өстәмә профессиональ белем алган, яки авыл хуҗалыгында өч елдан ким булмаган стажлы, яки шәхси хуҗалык эшен өч ел дәвамында уртак эшләүче я үзе алып баручы була ала;

2.1.5. 2007 нче елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү хакында» Федераль закон нигезендә, заявка тапшыручы башлыгы булган КФХ микропредприятие критерийлары таләпләрернә туры килә;

2.1.6. Авыл хуҗалыгы продукциясен гамәлгә ашыруның күләмен арттыру Программасы нигезендә заявка тапшыручыда хуҗылыкны булдыру һәм үстерү эшчәнлеге (тармаклары) юнәлешләрен яктырткан план була (алда – бизнес-план);

2.1.7. Заявка тапшыручы сатып алыначак милекне (алда - сатып алынулар), башкарылачак эшләрне, аларның санын, бәясен, финанслау чыганакларны (грант, заем яки шәхси чыганакларны) яктырткан чыгымнар планын тәкъдим итә;

2.1.8. КФХ башлыгы чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алыначак һәр җиһазның бәясеннән 10 проценттан да ким түгел өлешен шәхси акчаларыннан түләргә ризалыгын бирә;

2.1.9. КФХ башлыгы үзенең счетына акчалар күчү көненнән башлап грант һәм (яки) акчалата ярдәмне 18 ай эчендә кулланачагын һәм грант һәм (яки) ярдәм акчаларына сатып алынган милекне бары тик хуҗалыкны үстерүгә тотачагын раслый;

2.1.10. КФХ башлыгы булган заявка тапшыручы грантның һәм (яки) акчалата ярдәмнең һәр 500 мең сумына кимендә бер даими (вакытлыча эшчеләрне, КФХ башлыгы һәм КФХ әгъзаларын исәпкә алмыйча) эш урыны булдыруны планлаштыра;

2.1.11. Заявка тапшыручы 30 мең сумнан артык суммага авыл хуҗалыгы продукциясен гамәлгә ашырачагы турындагы гражданлык-хокукый актлары (башлангыч килешүләре) төзегән;

2.1.12. Заявка тапшыручы грант һәм (яки) акчалата ярдәм алганнан соң кимендә биш ел дәвамында хуҗылыкның эшен гамәлгә ашырачагын раслый;

2.1.13. Россия Федерациясе законнары нигезендә заявка тапшыручы үзенең шәхси мәгълүматларын файдаланырга һәм эшкәртергә ризалыгын бирә;

2.1.14. Хуҗалык башлыгы булган заявка тапшыручы хуҗалыгы урнашкан яки регистрация үткән муниципаль берәмлектә яши яки әлеге берәмлеккә яшәргә күчүен раслый һәм әлеге хуҗалык аның бердән-бер эш урыны булып тора;

2.1.15. КФХның иминият взносларын түләү буенча сроктан чыккан бурычлары, пенялары, штрафлары булмаска тиеш.

Грант һәм (яки) акчалата ярдәм КФХ башлыгына бары тик бер генә тапкыр бирелә.

## 3. Программада катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырылырга тиешле документлар исемлеге

3.1. Заявка тапшыручы конкурста катнашу өчен түбәндәге документлар тапшыра:

3.1.1. Әлеге Нигезләмәнең 1нче номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча заявка;

3.1.2. Әлеге Нигезләмәнең 2нче номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча анкета;

3.1.3. Түбәндә аталган документларның булуына карап:

а) авыл хуҗалыгы олкәсендәге махсус урта яки югары белемне раслаучы документ күчерелмәсе;

б) заявка тапшыручының оч ел дәвамында шәхси хуҗалык эшен үзе я уртак башкаручы булу турында җирле үзидарә раслаган белешмә;

в) заявка тапшыручының авыл хужалыгы белгечлеге буенча 3 елдан ким булмаган стажны раслаучы хезмәт кенәгәсе күчерелмәсе, шул ук вакытта әлеге Нигезләмәнең 2.1.14нче пунктына туры килүне ачыклау өчен мәҗбүри рәвештә хезмәт кенәгәсенең оригинлы;

3.1.4. Әлеге Нигезләмәнең 3нче номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча үз эшен оештыруның бизнес-планы;

3.1.5. Заявка бирү көненә кадәр өч айдан иртәрәк алынган шәхси эшмәкәрләрнең Бердәм дәүләт реестрыннан күчерелмә;

3.1.6. КФХның дәүләт регистрациясе турында Таныклыгының күчерелмәсе;

3.1.7. Татарстан Республикасы буенча Федераль дәүләт статистика хезмәте территориаль бүлекчәсендәге дәүләт регистрациясе турында мөрәҗәгать хатының күчерелмәсе;

3.1.8. Россия Федерациясе гражданины паспорты копиясе;

3.1.9. Әлеге Нигезләмәнең 4нче номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча КФХны үстерүгә грант һәм көнкүрешякларны төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата ярдәм нигезендә уртак финанслауга тәкъдим ителгән чыгымнар планы;

3.1.10. КФХ сатып алачак һәр милек, һәр эшләнәчәк эш бәясенең 10 проңенттан да ким булмаган акчаның барлыгын раслаучы КФХ исәп-хисап счетыннан банк күчерелмәсе;

3.1.11. 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы «Росссия Федераңиясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү хакында» Федераль законның 4 нче пункты һәм әлеге Нигезләмәнең 5нче номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча үз эшен башлаучы фермерның микропредприятие параметрларына туры килүен раслаучы эшчеләрнең якынча саны турында белешмә;

3.1.12. 30 мең сумнан артык суммага авыл хуҗалыгы продукциясен гамәлгә ашырачагы турындагы башлангыч килешү;

3.1.13. Заявка тапшыру көненнән 30 көн эчендә бердәм дәүләт реестры тарафынана күчемсез милек һәм аның белән эш итүгә хокукы барлыгын раслаучы һәм КФХ башлыгында авыл хуҗалыгы җитештерү объектларының булуын раслаучы күчерелмәләре;

3.1.14. Локаль-смета исәпләве кергән җыелма-смета исәпләү белешмәсе һәм проект эшләрен башкарырга лицензиясе булган оешма тарафыннан төзелгән объект схемалары (грант һәм (яки) акчалата ярдәм төзү яки реконструкциягә каралган очракта);

3.1.15. Махсус җир мәйданнарында төзү эшләрен (реконструкция эшләрен) башкарырга рөхсәт кәгазе (грант һәм (яки) акчалата ярдәм төзү яки реконструкциягә каралган очракта);

3.1.16. Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турындагы законы нигезендә түләнергә тиешле срогыннан чыккан салым түләү буенча бурычлары, пенялары, штрафлары, процентлары юклыгын раслаучы салым органынан заявка тапшыру моментына 30 кон эчендә бирелгән белешмә;

3.1.17. Әлеге Нигезләмәнең 6нчы номерлы кушымтасында бирелгән форма буенча тутырылган шәхси мәгълүматларын эшкәртергә ризалык кәгазе;

3.1.18. КФХ башлыгының (башка муниңипаль берәмлектә яшәгән очракта) даими яшәү урыны буларак КФХ эшен алып барган муниципаль берәмлеккә күчү йөкләмәсе.

3.2. Тәкъдим ителгән документлардагы мәгълүматларның дөреслеге һәм чынга ашуы өчен җаваплылык заявка тапшыручыларга йокләнә.

3.3. Әлеге Нигезләмәнең 3.1.нче бүлегендә күрсәтелгән документлар (яки документлар күчерелмәләре) номер сугылганнан соң тегеп беркетелергә һәм КФХ башлыгы имзасы белән моһер сугылган (мөһер булган очракта) булырга тиеш.

Берничә биттән торган расланырга тиешле документлар тәкъдим ителгән очракта һәр бит расланырга тиеш. Документларның оригиналлары конкурс комиссиясенә проектны яклаган вакытта күчерелмәләрне чагыштыру очен тәкъдим ителә.

Төзәтүләр һәм үзгәртүләр кертү рөхсәт ителми, бары тик КФХ имзасы белән расланган һәм мөһер сугылган (мөһер булган очракта) төзәтүләрдән тыш. Әлеге Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документлар тиешле срокларда һәм хәбәрнамәдә (белешмәдә) күрсәтелгән тиешле адрес буенча бирелергә тиеш.

3.4. Программада потенциаль катнашучы күзлегеннән фермер хуҗалыкны уңай яктан бәяләгән башка төрле документларны заявка тапшыручылар, аларның конкурс комиссиясе карарына йогынты ясаячакларына ышанган очракта, өстәмә рәвештә тәкъдим итәргә мөмкин, мәсәлән:

а) тәкъдим итү хатларын;

б) техника паспортларының күчерелмәләрен (КФХ башлыгы милкендә техника булган очракта);

в) массакүләм информация чараларындагы публикацияләрне, объектларның фоторәсемнәрен һәм башка документларны.

Өстәмә бирелгән документлар заявка тапшырылганда шулай ук исемлеккә кертелергә тиеш.

Документлар тапшыру өчен тиешле срокларны бозып тапшырылган заявкалар кабул ителми.

3.5. Заявканы әзерләү һәм тәкъдим итүгә бәйле чыгымнар заявка тапшыручыларга йөкләнә.

3.6. Әлеге бүлекнең 3.1., 3.4. бүлекчәләрендә күрсәтелгән документлар Нигезләмәнең 7нче кушымтасындагы исемлек буенча тәкъдим ителә. Исемлек конвертка салынмый. Документлар кабул ителгәндә исемлеккә кабул ителү көнен күрсәтелә. Кабул ителү датасы булган исемлекнең бер экземпляры заявка тапшыручыда кала, икенчесе – конкурс комиссиясендә.

Заявка һәм документлар кабул ителгәндә аларның тулылыгы һәм куелган таләпләргә туры килүе тикшерелми.

3.7. Министрлык боерыгы нигезендә  үз эшен башлаучы фермерларга махсус бюджет акчаларын Нигезләмәнең 8нче кушмытасында бирелгән формада тәкъдим итү турындагы килешү беркетмәсе буенча грант һәм (яки) акчалата ярдәм үз эшен башлаучы фермерларга конкурс комиссиясе нәтиҗәсе буенча бирелә. Акчалата ярдәм үз эшен башлаучы фермерга:

йорт сатып алу, төзү һәм үз йортына ремонт ясау, шулай ук йорт сатып алырга банк тарафыннан бирелгән кредитларның (ипотеканың) төп суммасын һәм процентларын каплау;

йөк һәм пассажирлар йөртергә бер автомобиль сатып алу;

йорт җиһазлары, көнкүреш техникасы, компьютерлар, элемтә чаралары, электр һәм газ плитәләре, инженер җиһазлар, су чистарту өчен җайланмалар, көнкүреш су, җылылык һәм газ җайланмалар, сууткәргеч һәм су бирү җайланмаларын сатып алу;

торакларны газ, электр, элемтә, интернет, сууткәргеч һәм канализация челтәрләренә тоташтыру шарты белән бирелә.

3.8. Грант һәм (яки) акчалата ярдәм бирү федераль һәм Татарстан Республикасы бюджетларыннан финанслау лимитларын исәпкә алып башкарыла.

## 4. Завкаларны кабул итү һәм тикшерү

4.1. Грантлар һәм (яки) акчалата ярдәм алуның сайлап алу бәйгесендә катнашуга заявкаларны кабул итә башлау турында белдермә Министрлыкның http://argo.tatarstan.ru/ официаль сайтында урнаштырыла.

Катнашуга заявкалар сайлап алу бәйгесе турындагы белдермәдә күрсәтелгән адрес буенча бирелә. Белдермәдә бәйгене уздыру урыны һәм вакыты, контакт өчен телефоннар, документларны тапшыру тәртибе һәм бәйгенең шартлары, норматив документлар белән таныша алу мөмкинлеге турында мәгълүмат бирелгән Министрлык сайтындагы бүлеккә сылтама күрсәтелә.

4.2. Заявкаларны кабул итә башлау срогы – белдермәне игълан иткәннән соң киләсе көн. Заявкаларны кабул итүнең соңгы срогы – белдермәдә күрсәтелгән заявка тапшыруның срогы чыгуга.

4.3. Заявка тапшыручылар конкурс комиссиясенә әлеге Нигезләмәнең 3нче бүлеге таләпләренә туры китерелеп формалаштырырган заявкаларны тапшыра.

Заявка кәгазь вариантта конвертка салынып тапшырыла. Конверт конкурс комиссиясе сәркатибе тәкъдим ителгән документларны бирелгән тасвирлама белән чагыштыргач кына ябыштырыла һәм КФХ мөһере (мөһер булганда) куела. Конверт тышында программаның исеме, проект атамасы, КФХ атамасы, заявка тапшыручының исем-фамилиясе һәм адресы күрсәтелә. Заявкалар теркәү журналында теркәлергә тиеш.

4.4. КФХны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар бирү Һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм күрсәтү очен крестьян (фермер) хуҗалыклырны сайлап алу ведомствоара конкурс комиссиясе нигезләмәсе нигезендә конкурс комиссиясе сәркатибе:

номер сугылган, тегелгән һәм конкурс комиссиясе сәркатибе имзасы белән Министрлык мөһере куелган заявкаларны теркәү журналында заявкалар тапшырылу тәртибендә кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

завкаларны кабул итү туктау моментыннан өч эш көне дәвамында документлар белән заявкалар исемлеген төзи һәм аларны конкурс комиссиясенә тәкъдимнәр әзерләү өчен эксперт советына тикшерергә тапшыра;

эксперт совет беркетмәсен алганнан ике эш көне дәвамында конкурс комиссиясе утырышларының көн тәртибе буенча материаллар әзерләүне оештыра, документлар әйләнеше эшен һәм конкурс комиссиясе әгъзаларының утырышларда катнышуын булдыра;

конкурс комиссиясе утырышлары тәмамалануга ике эш көне дәвамында конкурс комиссиясе беркетмәләрен (алда – беркетмә) рәсмиләштерә;

конкурс тәмамлану белән 30 көнэчендә конкурсны узмаган заявкаларны, конкурс тарафыннан кабул ителгән барлык документларны Министрлык архивына биш ел дәвамында саклау өчен тапшыра;

4.5. КФХны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар бирү Һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм күрсәтү өчен крестьян (фермер) хуҗалыклырны сайлап алу Ведомствоара конкурс комиссиясе каршындагы Эксперт совет турындагы

Нигезләмәгә буенча каралган тәртиптә эксперт совет:

конвертлар ачуны башкара һәм документларның әлеге Нигезләмә билгеләгән тәртиптә булуын тикшерә,

КФХ башлыгының һәм ул тәкъдим иткән документларның әлеге Нигезләмә билгеләгән таләпләргә туры килүен тикшерә,

завкаларны кабул итү моментыннан 15 эш көне көненнән дә соңга калмыйча рекомендация характерындагы бәяләмә белән эксперт совет беркетмәсен конкурс комиссиясенә җибәрә.

4.6. Әлеге Нигезләмә буенча каралган заявкалар тапшыручыларга кире кайтарылмый һәм Программа гамәлгә ашу вакыты эчендә Министрлыкта саклана.

## 5. Сайлап алу этабын уздыру

5.1. Конкурс комиссиясе утырышлары эксперт совет белешмәләрен алуга биш эш көненнән дә соңга калмыйча, кергән заявкаларның санына карап мөрәҗәгать итүчеләрне график буенча әңгәмәгә чакырып, үткәрелә.

5.2. Мөрәҗәгать итүче 2.1-2.15. пунктларда билгеләнгән таләпләр нигезендә заявка тапшырганнан соң төзәтелгән документларны әңгәмәгә тәкъдим итәргә мөмкин.

5.3. Конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүчеләр тәкъдим иткән документларны бәяләгәндә барлыкка килгән сорауларны ачыклау өчен экспертлар һәм башка белгечләр чакырырга хокуклы.

5.4.Конкурс комиссиясе сайлап алуның җиңүчеләрен мөрәҗәгать итүчеләр проектларын яклау нигезендә, тәкъдим ителгән документларның тулы анализын ясап һәм эксперт совет белешмәсендәге тәкъдимнәрне исәпкә алып, билгели.

Мөрәҗәгать итүченең эш сыйфатына, оештыру сәләтенә, осталыгына, кредит тарихына, социаль һәм бюджет җаваплылыгына билге КФХ башлыгы белән туры әңгәмәдән соң куела, максималь билге – 20 балл.

Һәр бәяләнәчәк проектка әлеге пунктта саналган критерийлар буенча йомгаклау баллар суммасы чыгарыла. Максималь мөмкин баллар саны 20.

Конкурс комиссиясе мөрәҗәгать итүчеләрнең заявкалары 11дәнартыграк бал җыючыларга карата уңай нәтиҗә кабул итә.

Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан уңай карала торган заявкалар саны Татарстан Республикасы бюджеты һәм (яки) федераль бюджеты акчалары исәбеннән программаны тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләрнең бүлеп бирелгән лимитларыннан чыгып билгеләнә.

5.5. Сайлап алуны узмаган дип түбәндәге критерийларны узмаган мөрәҗәгать итүчеләр таныла:

проект 11дән ким балл җыйган очракта;

мөрәҗәгать итүче тарафыннан ялган йә махсус дөрес түгел мәглүмат тәкъдим ителгән очракта;

документлар Министрлык раслаган формаларга туры килмәгән очракта.

5.6. Конкурс нәтиҗәләре комиссия тарафынан соңгы әңгәмәдән соң ике эш көне үтү белән ясала. Конкурс комиссиясе карары комиссия составы яртысыннан күбрәк булган очракта гади күпчелек тавыш белән кабул ителә, тавышлар тигез булганда комиссия рәисе тавышы яки (ул булмаганда) конкурс комиссиясе рәисе урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора.

Берничә мөрәҗәгать итүченең баллар саны тигез булган очракта комиссия грантны завка тапшыру тәртибе буенча тәкъдим итә.

5.7. Конкурс комиссиясе нәтиҗәсе:

Конкурс комиссиясендәкатнашучы әгъзаларны;

тавыш биү нәтиҗәләрен;

сайлап алуда җиңүчеләрнең исемлеген;

грантның һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерга күрсәтеләчәк акчалата ярдәмнең суммасын күрсәтеп беркетмә белән рәсмиләштерелә.

5.8. Беркетмә конкурс комиссиясе рәисе, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе сәркатибе (тавыш бирергә хокуксыз) һәм конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана. Беркетмәгә конкурс комиссиясе әгъзаларының тавыш бирү турындагы җыелма исемлеге беркетелә.

5.8.1. Беркетмә имзалану белән биш көн эчендә Министрлык:

сайлап алу нәтиҗәләррен раслау турында боерык чыгара;

конкурста катнашучыларга мәгълүмат җиткерү өчен Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгы район авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә (алда – Идарә) конкурс комиссиясе кабул иткән нәтиҗәләр турында белдерү хаты җибәрә;

Министрлыкның http://argo.tatarstan.ru/ официаль сайтында катнашучылар һәм җиңүчеләр турында мәгълүмат урнаштыра.

5.9. Идарәләр конкурста катнашучыларга ике көн эчендә комиссия кабул иткән нәтиҗәләр турында мәгълүматны белдерү хаты аша җиткерә.

5.10. Конкурс комиссиясе һәм эксперт совет әгъзалары Россия Федерциясе законнары нигезендә мөрәҗәгать итүченең коммерция мәгълүматы конфиденциальлеген саклануы өчен җаваплы.

5.11. Конкурска тапшырылган завякаларның саны яки грант җиңгән һәм (яки) акчалата ярдәм алган фермерларның саны финансланырга тиешле фермерларның саныннан азрак булган очракта, Министрлык кулланылмаган акчаларга өстәмә конкурс игълан итә.

5.12. Грант һәм (яки) акчалата ярдәм алуга тапшырылган заявкалары кире кагылган(шулай ук техник хата очракта да) мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләрен тикшерү чираттагы конкурс комиссиясе утырышында тавыш бирү юлы белән үткәрелүе һәм конкурс комиссиясе Беркетмәсендә теркәлүе турында морәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

5.13. Грантка ия булучының:

а) әлеге Нигезләмәнең 4нче кушымтасы нигезендә күрсәтелгән формада грант һәм (яки) акчалата ярдәм аша уртак финанслауга тәкъдим ителә торган чыгымнар планын үзгәртү турында;

б) әлеге Нигезләмәнең 3нче кушымтасы һәм үз эшен башлау турында үзгәртелгән Бизнес-план нигезендә күрсәтелгән формада эшчәнлек юнәлешләрен үзгәртү турында;

в) гран һәм (яки) акчалата ярдәмне файдалану турында Идарәгә хисап тапшыруга муниципаль районны үзгәртү турында

гаризасын комиссия әгъзалары тавыш бирү юлы белән чираттагы конкурс комиссиясе утырышында карау башкарыла һәм Конкурс комиссиясе утырышы Беркетмәсендә теркәлә.

## 6. Грант һәм акчалата ярдәмне күчерү һәм кире кайтару тәртибе

6.1. Грант күләмен 1500 мең сум, акчалата ярдәмнең – 250 мең сум күләмен расларага.

Бер КФХка грант һәм (яки) акчалата ярдәм берьюлы бирелгәндә дәүләт тарафаннан бирелә торган ярдәм өлешенең гомуми суммасы 1500 мең сумнан артырга тиеш түгел.

6.2. Заявкалары сайлап алу турын узган үз эшен башлаучы фермарлар (алда – грант алучылар) сайлап алу нәтиҗәләре турында беледерү хатын алу белән биш эш көне эчендә Министрлыкка түбәндәге документларны тәкъдим итә:

а) Министрлык боерыгы белән расланган тиешеле формада грант һәм (яки) акчалата ярдәм күләмен күрсәткән исап-хисап белешмә;

б) Конкурс көмиссия раслаган юнәлешләр киселешендә чыгымнар планы;

в) әлеге Нигезләмәнең 8нче кушымтасы нигезендә КФХ башлыгы тарафыннан расланган КФХ үсешенә грант һәм көнкүреш ягын төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата ярдәмне бирү турында килешү.

6.3. Министрлык документларны алу белән биш эш көне дәвамында аларны тикшерә һәм грант һәм (яки) акчалата ярдәм күләмен күрсәткән исап-хисап белешмәләрне, чыгымнар планын һәм әлеге Нигезләмәнең 6.2. пункты буенча грант алучылар тарафыннан тәкъдим ителгән килешүләрне имзалый.

6.4. Грант һәм (яки) акчалата ярдәмне грант алучыларның кредит оешмаларда ачылган расчет счетларына күчерү өчен Министрлык Татарстан Республикасы финанслар Министрлыгының казначылык Депаратаментына:

6.4.1. конкурс көмиссиясе беркетмәсен раслау турында Министрлык боерыгын;

6.4.2. һәр үз эшен башлаучы фермерның грант һәм (яки) акчалата ярдәме күләмен күрсәткән исап-хисап белешмәсен һәм әлеге Нигезләмәнең 6.2. пункты нигезендә грант бирү турындагы килешүнең күчермәсен тапшыра.

6.5. Грант һәм (яки) акчалата ярдәмне максатчан кулллануны тикшерүне Министрлык башкара.

6.6. Максатка туры китереп кулланмау, грант һәм (яки) акчалата ярдәм алу очен фактларга туры килмәгән мәгълүмат һәм документлар тапшыру очраклары ачыкланганда тәкъдим ителгән грант һәм (яки) акчалата ярдәм суммасы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетларына Министрлыкның тиешле күрсәтмәсен алу белән 60 көн эчендә кайтарылырга тиеш.

6.7. Грант алучылар грант һәм (яки) акчалата ярдәмнән баш тарткан очракта акчалар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетларына хисап тотыла торган елдан соң килгән 1 февральгә кадәр кайтарылырга тиеш.

6.8. Хисап тотыла торган финанс елда кулланылмаган Министрлык счетларныда калган акчалар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы бюджетларына хисап тотыла торган елдан соң килгән 1 февральгә кадәр кайтарылырга тиеш.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
Министрлыгының 2015 елның 17 мартындагы
50/2-пр номерлы боерыгына 3нче кушымта
(ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
Министрлыгының 2016 елның 26нчы
гыйнварындагы 5/2-пр номерлы
боерыгы редакциясендә)

КФХны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар
һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә
бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирелергә тиешле
крестьян (фермер) хуҗалыкларны сайлап алу буенча
ведомствоара конкурс комиссиясе турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Крестьян (фермер) хуҗалыкларны (алда – КФХ) булдыру һәм аларның үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирелергә тиешле КФХны сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясе (алда – конкурс комиссиясе) Россия Федерациясе авыл хуҗалыгы Министырлыгының «Россия Федерациясе хөкүмәтенең 2012 елның 28 февралендәге 166 номерлы карарын гамәлгә ашыру турында» 2012 елның 22 мартындагы 197 номерлы боерык һәм «2015-2017 нче елларда Татарстан Республикасында үз эшен башлаучы фермерларга ярдәм күрсәтү» ведомство программасы (алда – Программа) нигезендә булдырылды.

1.2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары:

заявка тапшыручы тарафыннанан КФХ үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм (алда – грант) алу өчен тапшырылган конкурс документациясен вакытында, ачык һәм объектив карау;

проектларның тулылыгын һәм чынга ашуын ачыклау өчен экспертиза үткәрү;

Татарстан Республикасы икътисады өчен икътисади эффектын, соціаль әһәмиятен ачыклау;

дәүләт ярдәмен күрсәтү кирәклеген ачыклау;

конкурста җиңүчеләрне һәм аларга тәкъдим ителә торган грантларның күләмен билгеләү.

## 2. Конкурс комиссиясенең составы, вәкаләтләре һәм җаваплылыгы

2.1. Конкурс комиссиясе Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгы (алда – Министрлык) боерыгы нигезендә кимендә 12 кешедән төзелә һәм рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатибтән (тавыш бирүгә хокуксыз), конкурс комиссиясе әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясе составында дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең саны 50 проценттан артык булмаска тиеш.

2.2. Конкурс комиссиясе әгъзасы конкурс комиссясе составыннан конкурс комиссиясе рәисе исеменә үзенең карары турында язмача гариза җибәреп, чыгарга хокуклы.

2.3. Конкурс комиссиясе составына үзгәрешләр Министрлык һәм конкурс комиссиясе рәисе инициативасы белән кертелә.

2.4. Конкурс комиссиясе рәисе:

конкурс комиссиясе эшен җитәкли һәм аңа йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен җаваплы,

конкурс комиссиясе әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә,

конкурс комиссиясе утырышларын алып бара,

утырышларның беркетмәләрен әзерләүне һәм конкурс комиссиясе кабул иткән караларның үтәлешен контроль астында тота.

2.4.1. Конкурс комиссия утырышларында рәис булмаган очракларда конкурс комиссиясе рәисе урынбасары аның вазыйфаларын башкара.

2.4.2. Конкурс комиссиясе сәркатибе:

номер сугылган, тегелгән һәм конкурс комиссиясе сәркатибе имзасы белән Министрлык мөһере куелган заявкаларны теркәү журналында заявкалар тапшырылу тәртибендә кабул итүне һәм теркәүне оештыра;

завкаларны кабул итү туктау моментыннан оч эш көне дәвамында документлар белән заявкалар исемлеген төзи һәм аларны КФХ үсешенә грант һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерның конкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирелергә тиешле КФХны сайлап алу буенча Ведомствоара конкурс комиссиясе каршындагы эксперт советка тикшерергә һәм конкурс комиссиясенә тәкъдимнәр әзерләү өчен тапшыра;

эксперт совет беркетмәсен алганнан ике эш коне дәвамында конкурс комиссиясе утырышларының көн тәртибе буенча материаллар әзерләүне оештыра, документлар әйләнеше эшен һәм конкурс комиссиясе әгъзаларының утырышларда катнышуын булдыра;

конкурс комиссиясе утырышлары тәмамалануга ике эш көне дәвамында конкурс комиссиясе беркетмәләрен (алда – беркетмә) рәсмиләштерә;

конкурс тәмамлану белән 30 көн эчендә конкурсны узмаган заявкаларны, конкурс тарафыннан кабул ителгән барлык документларны Министрлык архивына биш ел дәвамында саклау өчен тапшыра.

2.5. Йокләнгән вазыйфаларны башкару очен конкурс комиссиясе тәкъдим ителгән проектлар буенча консультация алу, аларны өйрәнү һәм экспертизалау, бизнес-планның финанс мөмкинлеген ачыклау йөзеннән экспертлар һәм белгечләр чакырырга хокуклы.

2.6. Конкурс комиссиясе:

тапшырылган заявкаларны һәм заявка тапшыручыларның документларын тикшерә һәм үткәрелгән конкурс нәтиҗәсендә ике эш көне дәвамында җиңүчеләрне билгели;

конкурсның сайлап алу этабын узган заявка тапшыручыларга үзләренең акчаларын һәм чыгымнар планын, чыгымнар юнәлешләренең нигезлелеген исәпкә алып, КФХ үсешенә грант һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерның конкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм

күрсәтүнең күләмен билгели;

эшмәкәрлек эшчәнлегенең шартлары үзгәрүе грант һәм бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәмне чыгымнар планы нигезенедә объектив сәбәпләр буенча кулланырга комачаулауга китерсә, күрсәтелгән үзгәрешләрне килештерү турында карар кабул итә;

үз вәкаләтләре чикләрендә, министрлыклардан, ведомстволардан, муниципаль берәмлек администрацияләреннән, оешмалардан, банклардан, аудит фирмаларыннан, башка финанс институтлардан конкурс үткәрүгә бәйле сораулар буенча материаллар соратырга мөмкин.

2.7. Конкурс комиссия әгъзалары закон нигезендә заявка тапшыручының коммерция бәйле мәгълүматларының конфиденциальлеге өчен җаваплы.

2.8. Конкурс комиссиясе утырышлары кирәк булу белән үткәрелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары утыршка конкурс рәисе карары буенча чакырыла. Утырышка өч көн кала конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясе әгъзаларына каралырга тиешле заявкаларны җибәрә.

2.9. Конкурс комиссиясе утырышларында конкурс комиссиясе әгъзалары яртысыннан артыграк булган очракта утырышлар хокуклы.

2.10. КФХ үсешенә грант һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм күрсәтү Нигезләмәсенең 5.4. пункты нигезендә конкурсның җиңүчеләре ачыклана.

2.11. Заявкаларны һәм документларны тикшерү нәтиҗәсеннән һәм, шулай ук, заявка тапшыручыларның проектларын яклавыннан чыгып (туры әңгәмә), конкурс комиссиясе карарлары беркетмә белән рәсмиләштерелә, конкурс комиссиясе рәисе, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары, конкурс комиссиясе сәркатибе (тавыш бирергә хокуксыз) һәм конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан имзалана.

КФХ үсешенә грант һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм тиешле крестьян (феремер) хуҗалыкны сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Әхмәтов Марат Готоф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, конкурс комиссиясе рәисе |
| Хәбипов Ришат Рәшит улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, конкурс комиссиясе рәисе урынбасары |
| Нәбиуллина Гөлсинә Нотфулла кызы | Министрлыкның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлегенең 1нче разрядлы өлкән белгече, конкурс комиссиясе сәркатибе (тавыш бирергә хокуксыз) |
| Конкурс комиссиясе әгъзалары | |
| Байтемиров Камияр Миҗагит улы | Татарстан крестьян хуҗалыклары һәм фермерлар Ассоцияцниясе рәисе (килешү буенча) |
| Гарифуллина Фәридә Галимҗан кызы | Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы эшчеләренең профсоюз оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Гафуров Илдар Шәүкәт улы | Министрлыкның инвестция сәясәте һәм максатчан программалар бүлеге башлыгы |
| Гыйләҗев Рәсил Васил улы | Министрлыкның аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге башлыгы |
| Нигъмәтҗанов Сирен Мулланур улы | Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы |
| Низаметдинов Марат Миңгали улы | Министрлыкның икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлеге башлыгы |
| Хафизова Элеонора Борисовна | Татарстандагы «Агробизнес өлкәсендә эшләүче кадрларны яңадан әзерләү институты» укыту-методик эш буенча проректоры (килешү буенча) |
| Шәрәфетдинов Газимҗан Сәлим улы | «Казан дәүләт аграр университеты» «Биотехнология, терлекчелек һәм химия» кафедрасы профессоры, авыл хуҗалыгы фәннәре докторы |
| Мадышев Илгиз Шамил улы | Н.Э. Бауман исемендзге «Казан дәүләт ветеринар медицина акдемиясе» «Икътисад, оештыру, менеджмент һәм информацион технологияләр» кафедрасы доценты, б.ф.к. |

| | |
|---|---|
| Григорьев Алексей Евгеньевич | «Россельхозбанк» Татарстандагы региональ филиалы директоры урынбасары |
| Парфенова Лариса Александровна | Дәүләт казна оешмасы каршындагы «Татарстан Республикасы кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү һәм ярдәм итү программасының гамәлгә ашыру үзәге» җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Хәлиуллин Хәйдәр Хәйрулла улы | Татарстан Республикасы кече һәм урта бизнес эшмәкәрлек оешмаларының Ассоциациясе президенты |

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының 2015 елның 17 мартындагы 50/2-пр номерлы боерыгына 5нче кушымта (ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгының 2016 елның 26нчы гыйнварындагы 5/2-пр номерлы боерыгы редакциясендә)

КФХны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирелергә тиешле крестьян (фермер) хуҗалыкларны сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясе каршындагы эксперт совет турында
НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Крестьян (фермер) хуҗалыкларны (алда – КФХ) булдыру һәм аларның үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирелергә тиешле КФХны сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясе каршындагы эксперт совет «2015-2017 нче елларда Татарстан Республикасында үз эшен башлаучы фермерларга ярдәм күрсәтү» ведомство программасы (алда – Программа) буенча конкурс сайлап алуга тәкъдим ителгән документларга экспертиза үткәрү өчен төзелә.

1.2. Эксперт совет Программа гамәлдә булган чорда төзелә һәм эшли. Эксперт советның эшләү тәртибе әлеге КФХны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирелергә тиешле крестьян (фермер) хуҗалыкларны сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясе каршындагы эксперт совет турындагы Нигезләмә белән билгеләнә (алда – Нигезләмә).

## 2. Эксперт совет вәкаләтләре

2.1. Эксперт совет билгеләнгән эшчәнлек сферасы буенча түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

Нигезләмәдә билгеләнгән һәр критерий буенча заявкаларга эксперт бәяләү ясый;

завкаларны кабул итү моментыннан 15 эш көне көненнән дә соңга калмыйча КФХны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм бирелергә тиешле КФХны сайлап алу буенча ведомствоара конкурс комиссиясенә (алда – конкурс комиссиясе) тәкъдим характерындагы бәяләмә белән эксперт совет утырышы беркетмәсен тапшыра.

## 3. Эксперт совет составы

3.1. Эксперт совет Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек Министрлыгы (алда – Министрлык) боерыгы нигезендә кимендә 12 кешедән төзелә һәм рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатибтән (тавыш бирүгә хокуксыз), конкурс комиссиясе әгъзаларыннан тора.

3.2. Эксперт совет рәисе эксперт советка йөкләнгән бурычларның башкарылуы өчен шәхси җаваплылык тота.

3.3. Эксперт совет әгъзасы эксперт совет составыннан, эксперт совет рәисе исеменә үзенең карары турында язмача гариза җибәреп, чыгарга хокуклы.

3.4. Эксперт совет составына үзгәрешләр Министрлык һәм конкурс комиссиясе рәисе инициативасы белән кертелә.

## 4. Эксперт совет эшен оештыру

4.1.1. Эксперт совет рәисе:

эксперт совет эшчәнлеген җитәкли һәм аңа йөкләнгән бурычларның үтәлеше өчен җаваплы;

эксперт совет сәркатибеннән тапшырылган заявкалар саны турында мәгълүмат ала һәм аларны эшкәртү тәртибен килештерә;

программада катнашучылар тәкъдим иткән документларга экспертиза үткәрү өчен эксперт совет әгъзалары арасында вазыйфаларны бүлә;

эксперт совет эше белән гомуми җитәкчелек итә;

эксперт совет утырышларының көн тәртибен әзерли;

эксперт совет утырышларын алып бара;

эксперт совет беркетмәләрен имзалый.

4.1.2. Эксперт совет рәисе булмаган очракларда эксперт совет рәисе урынбасары аның вазыйфаларын башкара.

4.1.3. Эксперт совет сәркатибе:

исемлек буенча тапшырылган заявкаларны кабул итә;

эксперт совет әгъзаларына эксперт бәяләмә кирәкле заявкаларны җиткерә;

эксперт совет утырышларын оештыра;

эксперт совет әгъзаларына кирәкле мәгълүмати материалларны һәм документларны тәкъдим итә;

завкалар тикшерүгә кабул ителү белән 15 көн эчендә эксперт совет беркетмәсен имзалауны башкара һәм эксперт совет утырыш беркетмәсен конкурс комиссиясенә тапшыра.

4.1.4. Эксперт совет әгъзалары:

документлар пакетының тулы булуын (булмавын), алардагы мәгълүматларның дөреслеккә туры килүен (килмәвен) тикшерәләр;

документларның Министрлык раслаган формаларга туры килүен (килмәвен) тикшерәләр;

заявка тапшыручының КФХны булдыру һәм аларның үсешенә грантлар һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерларның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә

тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм күрсәтү турындагы Нигезләмәсе 2.1-2.15. пуктларына туры килүен (килмәвен) тикшерәләр;

эксперт кәгазьләрен тутыралар һәм имза куялар;

эксперт бәяләмәгә материаллар кабул ителеп 14 эш көне эчендә экскперт совет сәркатибенә тутырылган эксперт кәгазьләрен тапшыралар.

4.2. Эксперт совет утырышларын уздыру тәртибе:

4.2.1. Эксперт совет утырышлары заявкалар кабул итү турындагы белдермәдә күрсәтелгән соңгы көнгә кадәр 3 эш көне калганчы үткәрелә;

4.2.2. Эксперт совет рәисе яки (ул булмаган очракта) эксперт совет рәисе урынбасары эксперт совет утырышының көн тәртибен, вакытын һәм урынын билгели, эксперт совет беркетмәсен имзалый.

Утырышка чакырылышны эксперт совет сәркатибе башкара. Эксперт совет утырышының көн тәртибе, вакыты һәм урыны турындагы информация эксперт совет әгъзаларына утырышка ике көн кала бирелә.

4.2.3. Эксперт совет утырышларында эксперт совет әгъзалары яртысыннан артыграк булган очракта утырышлар хокуклы. Эксперт совет әгъзалары утырышта каралган сораулар буенча фикер алышканда тигез хокукка ия.

4.2.4. Эксперт совет карарлары утырышта катнашучы эксперт совет әгъзалары яртысыннан артыграгы уңай тавыш биргән очракта кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта рәис тавышы яки (ул булмаган очракта) рәис урынбасары тавышы хәлиткеч булып тора.

4.2.5. Эксперт совет карарлары эксперт совет рәисе, эксперт совет рәисе урынбасары, эксперт совет сәркатибе һәм эксперт совет әгъзалары тарафыннан имзалаган беркетмә белән рәсмиләштерелә,

Беркетмәдә утырышның үткәрелү көне һәм вакыты, эксперт совет әгъзаларының составы (фамилиясе һәм инициаллары) һәм утырышта катнашкан башка затларның исемлеге (фамилиясе һәм инициаллары, эш урыны һәм башкарган вазыйфасы), утырышның көн тәртибе һәм кабул ителгән тәкъдимнәр күрсәтелә.

КФХ үсешенә грант һәм (яки) үз эшен башлаучы фермерның көнкүреш якларын төзекләндерүгә бер генә тапкыр күрсәтелә торган акчалата ярдәм күрсәтүгә тиешлезаявкаларны тикшерү буенча эксперт совет составы

| | |
|---|---|
| Габдрахманов Илдус Харис улы | Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары, эксперт совет рәисе |
| Молокин Александр Николаевич | Министрлыкның агросәнәгать предприятелерәнең структурасын үзгәртү һәм агробизнесны үстерү бүлеге башлыгы, эксперт совет рәисе урынбасары |
| Фаткуллов Илгиз Фирдүс улы | Министрлыкның агросәнәгать предприятелерәнең структурасын үзгәртү һәм агробизнесны үстерү бүлеге шәхси ярдәмчел хуҗалыкларны, крестьян-фермер хуҗалыкларны һәм кооперативларны үстерү секторында әйдәп баручы белгеч, эксперт совет сәркатибе |
| Эксперт совет әгъзалары | |
| Баязитов Гөлүс Сәлим улы | Министрлыкның терлекчелек тармакларын үстерү бүлеге башлыгы урынбасары |
| Злобин Сергей Николаевич | Министрлыкның финанслау бүлеге башлыгы урынбасары |
| Нигемәтҗанов Газинур Әхмәтҗан улы | Министрлыкның бухгалтерлык исәп һәм хисаплылык бүлеге башлыгы урынбасары |
| Хөсәенов Айрат Шәүкәт улы | Министрлыкның инвестиция сәясәте максатчан программалр бүлеге башлыгы урынбасары |
| Яшин Дмитрий Александрович | Министрлыкның игенчелек тармакларын үстерү бүлеге орлыкчылык һәм химияләү бүлекчәсе башлыгы |
| Габбасов Илнар Хатыйф улы | Министрлыкның агросәнәгать комплексын инженерлык техникасы белән тәэмин итү бүлеге терлекчелек объектларын механизацияләү һүм энергия ресурслары бүлекчәсе башлыгы |
| Горшунов Дмитрий Валерьевич | Министрлыкның икътисади анализ һәм планлаштыру бүлеге әйдәп бару киңәшчесе |
| Петрова Ольга Алексеевна | Министрлыкның агросәнәгать предприятелерәнең структурасын үзгәртү һәм агробизнесны үстерү бүлеге әйдәп баручы киңәшчесе |
| Кадырова Гүзәл Хайбрахман кызы | Министрлыкның кадрлар бүлеге әйдәп баручы белгече |
| Галимҗанов Алмаз Илдус улы | Министрлыкның аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлеге үйдәп баручы консультанты |
| Вавилова Марина Александровна | Министрлыкның җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлегенең 1нче разрядлы өлкән белгече |
| Ризаева Гөлфирә Зыятдин кызы | Татарстан Республикасы «Агрокредитсоюз» авыл кредит кулланучылар кооперативлары союзы башкарма директоры (килешү буенча) |